**ГЛАВА ШАПШИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422708, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Шапши, ул.Ленина, 1

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШӘПШИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422708, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Шәпши авылы, Ленин ур, 1

Тел./факс: +7(84365) 77-2-36, e-mail: Shap.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«05» октябрь 2022 ел № 1

**Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлегенең Тимошкино торак пунктында гражданнарының үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 2131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлеге Уставының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 22 маддәсе һәм 23.10.2009 ел, №163 карары (08.05.2020 ел, 09.10.2020 ел, №6 редакциясендә) нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлеге башлыгы

**КАРАРЫ:**

1. 2022 елның 16 октябрендә 11.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлегенең Тимошкино торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлегенең Тимошкино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2023 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

1.Тимошкино торак пунктының урам утларын ремонтлау;
2.Тимошкино торак пунктының сууткәргеч челтәрләрен ремонтлау;
3.Тимошкино торак пунктының су башнясын коймалау

**«ӘЙЕ»** **«КАРШЫ».**

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән 10 көн эчендә халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек башлыгы ____________ В.А.Беляков